ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

06 августа 2020г. № 3802

Башкарма комитетның «2020-2022 елларга муниципаль яшьләр программасын раслау турында» 2019 елның 30 октябрендәге 5596 номерлы крарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар турында нигезләмәнең 5.24 пункты, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «2020-2022 елларга муниципаль яшьләр программасын раслау турында» 2019 елның 30 октябрендәге 5596 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Башкарма комитетның финанс идарәсенә 2020-2022 елларга муниципаль яшьләр программасында каралган чараларны финанслауны Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетының «Яшьләр сәясәте» 07.07 бүлеге (бүлекчәсе) буенча каралган акчалар хисабына 2020 елга – 136 580,23 мең сум, 2021 елга – 135 117,76 мең сум, 2022 елга – 135 234,59 мең сум күләмендә тәэмин итәргә.»;

2) 2020-2022 елларга муниципаль яшьләр программасын кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы И.А. Сәгыйдуллинага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

Башкарма комитетның
2020 елның 6 августындагы
3802 номерлы карарына
кушымта

# 2020-2022 елларга
# муниципаль яшьләр программасы

Татарстан Республикасы
Яр Чаллы шәһәре

1 бүлек. 2020-2022 елларга муниципаль яшьләр программасының паспорты

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | 2020-2022 елларга муниципаль яшьләр программасы (алга таба – программа) |
| Программаны эшләү нигезләре | «Иҗтимагый берләшмәләр турында» 1995 елның 19 маендагы 82-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>«Яшьләр һәм балалар иҗтимагый оешмаларына дәүләт ярдәме күрсәтү турында» 1995 елның 28 июнендәге 98-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>«Хәйрия эшчәнлеге һәм иреклелек (волонтерлык) турында» 1995 елның 11 августындагы 135-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>«Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында» 1998 елның 24 июлендәге 124-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>«Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы нигезләре турында» 1999 елның 24 июнендәге 120-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>«Россия Федерациясендә эшмәкәрләрнең хокукларын яклау буенча вәкаләтлеләр турында» 2013 елның 7 маендагы 78-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>«2016-2020 елларга Россия Федерациясе гражданнарына патриотик тәрбия бирү» дәүләт программасы турында» 2015 елның 30 декабрендәге 1493 номерлы карары;<br>Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2025 елга кадәр чорга Россия Федерациясенең Дәүләт яшьләр сәясәте нигезләрен раслау турында» 2014 елның 29 ноябрендәге 2403-р номерлы боерыгы;<br>Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2025 елга кадәр чорга Россия Федерациясендә тәрбия бирүне үстерү Стратегиясен раслау турында» 2015 елның 29 маендагы 996-р номерлы боерыгы;<br>Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2025 елга кадәр чорга Россия Федерациясенең Дәүләт яшьләр сәясәте нигезләрен тормышка ашыру буенча чаралар планы турында» 2015 елның 12 декабрендәге 2570-р номерлы боерыгы;<br>Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә иреклелекне (волонтерлыкны) үстерү концепциясен раслау |

| | |
|---|---|
| | турында» 2018 елның 27 декабрендәге 2950-р номерлы боерыгы;<br>Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында яшьләр һәм дәүләт яшьләр сәясәте турында» 1993 елның 19 октябрендәге 1983-XII номерлы законы;<br>Татарстан Республикасының «Иреклелек (волонтерлык) өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 30 июнендәге 48-ЗРТ номерлы Закон;<br>Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында балаларның һәм яшьләрнең интеллектуаль-иҗади потенциалын үстерү Концепциясе «Перспектива» турында» 2012 елның 9 октябрендәге УП-862 номерлы Указы;<br>Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль учреждениеләр тарафыннан күрсәтелә (башкарыла) торган һәм Татарстан Республикасында бюджетара мөнәсәбәтләрне формалаштырганда исәпкә алына торган муниципаль хезмәтләрнең (эшләрнең) якынча исемлеген раслау турында» 2015 елның 5 сентябрендәге 638 номерлы карары;<br>Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең гомумроссия база (тармак) исемлекләренә (классификаторларына) кертелмәгән дәүләт (муниципаль) хезмәтләренең һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында (муниципаль хокукый актларда) күздә тотылган, шул исәптән Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтләрен һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының уртак карамагындагы предметлар буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда күрсәтелә һәм башкарыла торган эшләрнең региональ исемлеген (классификаторын) раслау турында» 2018 елның 24 декабрендәге 1214 номерлы карары;<br>Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 номерлы карары |
| Программаны төп эшләүче | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе |
| Программаны башкаручылар | Программаның координаторы булып Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе тора.<br>Төп башкаручылар: Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе, Башкарма комитет районнар |

<table>
<tr><td></td><td colspan="5">хакимиятләренең мәгариф, мәдәният һәм яшьләр белән эшләү бүлекләре, Башкарма комитетның мәдәният идарәсе, Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе</td></tr>
<tr><td>Программаның максаты</td><td colspan="5">Яшьләрне социализацияләү һәм үз-үзләрен нәтиҗәле реализацияләү өчен тиешле шартлар булдыру, әлеге шартларны ресурслар белән тәэмин итү һәм яшьләрне социаль яклау гарантияләрен булдыру.</td></tr>
<tr><td>Программаның бурычлары</td><td colspan="5">1) балаларның, яшүсмерләрнең һәм яшьләрнең ялын оештыру;<br>2) яшүсмерләрнең һәм яшьләрнең асоциаль һәм деструктив тотышларын профилактикалауга юнәлдерелгән чаралар оештыру, социаль-куркыныч хәлдәге балаларга һәм яшьләргә ярдәм күрсәтү;<br>3) балаларда һәм яшьләрдә эшмәкәрлек күнекмәләре формалаштыру максаты белән аларны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру һәм эшмәкәрлек нигезләренә практик өйрәтүне оештыруга ярдәм итү;<br>4) Яр Чаллы шәһәрендә дәүләт яшьләр сәясәте активистлары кадрлар резервына ярдәм итү һәм аны үстерү</td></tr>
<tr><td>Программаны тормышка ашыру сроклары һәм этаплары</td><td colspan="5">2020 - 2022 еллар</td></tr>
<tr><td rowspan="6">Еллар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләме һәм чыганаклары</td><td rowspan="2">Финанслау чыганаклары</td><td colspan="4">Программаны тормышка ашыру еллары</td></tr>
<tr><td>1 нче ел/ мең сум</td><td>2 нче ел/ мең сум</td><td>3 нче ел/ мең сум</td><td>Барлыгы мең сум</td></tr>
<tr><td>Муниципаль бюджет</td><td>136580,23</td><td>135117,76</td><td>135234,59</td><td>406932,58</td></tr>
<tr><td>Республика бюджеты</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>Федераль бюджет</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td colspan="5">Программаны тормышка ашыруга тотылучы чыгымнар күләменә шәһәр бюджеты мөмкинлекләреннән чыгып, инфляция процесслары һәм Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендәге икътисадый хәлдән чыгып, төгәллекләр һәм төзәтмәләр кертелергә мөмкин</td></tr>
</table>

| | |
|---|---|
| Программаны тормышка ашыруның көтелгән нәтиҗәләре һәм нәтиҗәлелек күрсәткечләре | Программа 2020-2022 елларга муниципаль яшьләр программасы чараларына җәлеп ителгән 14 яшьтән 30 яшькә кадәрге яшьләрнең санын Яр Чаллы шәһәрендәге яшьләрнең гомуми санына карата 76,5 % итеп сакларга мөмкинлек бирәчәк |
| Программаны тормышка ашыруга контрольне оештыру системасы | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе |

## 2 бүлек. Проблеманың эчтәлеге һәм аны программа ысулы белән хәл итү кирәклеген нигезләү

Муниципаль яшьләр сәясәте шәһәрнең яшь буыны потенциалын формалаштыруның, үстерүнең һәм актив файдалануның мөһим инструменты булып тора.

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә дәүләт яшьләр сәясәте Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе эшчәнлеге аша тормышка ашырыла, аңа «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 34 пункты нигезендә балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча чараларны оештыру һәм гамәлгә кертү функцияләре йөкләнгән.

Шәһәрдә яшьләр сәясәте җирле үзидарә органнарының, төрле милек формасындагы учреждение һәм оешмаларның, иҗтимагый берләшмәләрнең тырышлыкларын берләштерүне, күпләп бюджеттан тыш финанслар җәлеп итүне, яңа идарә технологияләре кертүне күздә тотучы программа - максатчан ысул нигезендә гамәлгә кертелә.

Программаның актуальлеге һәм аны гамәлгә ашыру тормыш зарурлыгына бәйле – бүгенге көндә яшь кешеләрнең социаль кәефендә ике тенденция ачык күренә:

1. Яшьләр үз көчләренә ныграк ышана башладылар, аларның тормыш проблемаларын хәл итүгә әзерлек дәрәҗәсе үсте, алар үзләренең тормыш перспективаларын һәм тормыш максатларына ирешү мөмкинлекләрен ачык күрәләр.

2. Шомлану һәм тиз кызып китүчәнлек, арыганлык, тормыш һәм киләчәк өчен курку, уңышсызлыкларга борчылу.

Яшьләр арасында таралган үз-үзеңне асоциаль тоту киләчәк буын өчен элеккечә куркыныч тудыра: алкоголь һәм психоактив матдәләр куллану, тәмәке тарту, иртә җенси мөнәсәбәтләр, яшьләр криминаль субкультуралары.

Үз-үзләрен болай тотуның социаль куркынычы шунда, тормыш тәҗрибәсе булмаган, алкоголизм, наркоманлык, агрессиянең нәтиҗәләрен алдан күрә белмәгән яшь кешеләр, аларны нормадан тайпылу дип санамый.

Аларның массакүләм таралуы яшүсмерләрдә мондый хәл нормаль дигән иллюзия тудыра, һәм бу, ахыр чиктә, нәрсә теләсәң шуны эшләргә рөхсәт итүче үз «нормалары» булган үзгә яшүсмер-яшьләр субкультуралары формалашуга китерә.

XXI гасыр яшь буыны цифрлы яңа җәмгыятьтә үсте. Интернетта даими утыручы яшьләр озаклап басылып эшләргә күнекмәгән, алар импульсив, эзлекле түгел, артык эмоциональ, азартлы уеннарга, наркотикларга, алкогольгә, компьютер уеннарына бирелүчән һәм теләсә нинди, шул исәптән радикаль йогынтыга дучар булырга мөмкин.

Хәзерге буынның девизы: «Бөтенесе кебек бул!»: яшүсмер хәзер үзе булудан туктады, үл үзенең «мин» леген юкка чыгарды һәм «автоматка» әйләнде, ялгызлык һәм шомлану хисе кичерми. Алмашка анда бар да әйбәт һәм тыныч дигән иллюзия барлыкка килде.

Канәгатьлек хисе хезмәттән, тормышның төрле өлкәләренең тирәнлеге һәм эчтәлегеннән түгел, ә төрле яңа кискен тойгыларның алмашынып торуыннан туа.

Яшьләрнең энергиясенең тискәре чагылышын киметү өчен, ул энергияне кирәкле агымга кертергә һәм карьера, шәхси үсеш, позитив күнекмәләр формалаштыру өчен «социаль лифтлар» ясап, һәр кешегә үз теләгенә ирешү мөмкинлеге бирергә кирәк.

Хәзерге заман яшьләренең проблемалары дәүләт яшьләр сәясәтенең муниципаль дәрәҗәдәге өстенлекле юнәлешләрен билгели: яшьләрнең, балалар, яшьләр иҗтимагый берләшмәләренең иҗтимагый әһәмиятле инициативаларына, иҗтимагый файдалы эшчәнлегенә ярдәм күрсәтү; яшь гражданнарның икътисадый мөстәкыйльлеген тәэмин итүгә һәм аларның хезмәткә хокукларын гамәлгә ашыруга булышлык күрсәтү; яшь гаиләләргә дәүләт ярдәме күрсәтү; яшьләргә социаль хезмәт күрсәтү; яшь гражданнарның сәламәтлеген саклау, сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, аларны тәрбияләү һәм аларга белем бирү өчен шартлар тудыру.

Яшьләрнең дәүләт яшьләр сәясәтен формалаштыруда һәм тормышка ашыруда катнашуы әлеге программаның төп принципларыннан берсе булып тора.

Программаны тормышка ашыруның төп принциплары:

1) дәүләт яшьләр сәясәтенең тармакара өлкә буларак өстенлеге, барлык дәрәҗәдәге максатчан һәм инвестиция программаларын тормышка ашырганда муниципаль учреждениеләрнең материаль базасыннан файдалану;

2) яшьләрнең ихтыяҗларын һәм кызыксынуларын исәпкә алып, яшьләр сәясәте муниципаль учреждениеләре эшчәнлегенең профилен үзгәртү һәм яшьләр сәясәтенең заманча инфраструктурасын булдыру;

3) формаль булмаган субкультуралар белән үзара эшчәнлек каналлары булдыру;

4) очрашулар, «түгәрәк өстәлләр» оештыру, ел саен уза торган яшьләр инициативасы фестивальләрен үткәрү һәм укучы, эшче, иҗади, хезмәткәр яшьләрнең иҗтимагый берләшмәләрен төзүне стимуллаштыру аша «яшьләр белән диалог» оештырылу.

Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе яшь буында мәдәни, әхлакый кыйммәтләр, гражданлык позициясе тәрбияләп, күпкырлы интеллектуаль үсеш өчен шартлар тудырып, шәһәр потенциалын формалаштыру буенча мөһим юнәлешләрнең зур спектрын тормышка ашыра.

Программа чараларын уңышлы гамәлгә ашыру өчен яшьләр сәясәтенең муниципаль инфраструктурасы актив кулланыла: 4 яшьләр үзәге («Заман», «Шатлык», «Орион», «Нур»), 4 социаль учреждение («Диалог» БҺЯППЯҮ, «Яшьләр ышаныч телефоны» БЯТЭПЯҮ, «Яр Чаллы СХОҮ», «Форпост» ҖТСбЯБҮ), 26 яшүсмерләр-яшьләр клубы, «Экстрим-парк» һәм яшәү урыны буенча 14 хоккей корты, аларның төп эшчәнлеге булып яшүсмерләрнең ялын һәм мәшгульлеген оештыру, яшьләр арасында социаль тискәре күренешләрне профилактикалау һәм яшүсмерләр һәм яшьләр белән спорт-сәламәтләндерү эше алып бару тора.

Программаны тормышка ашыру нәтиҗәсендә, алдагы елларда Яр Чаллы шәһәрендә яшьләрдә актив һәм сәламәт яшәү рәвешенә, сәламәтлекне ныгыту, гражданлык позициясен, хезмәттәге һәм социаль активлыкны үстерү буенча озак сроклы максатларга ирешү өчен нигез булдырылган.

Хәзерге заман шартларында шәһәр яшьләр сәясәтенең төрле өлкәләре тирәнәйтүне һәм алга таба үсешне таләп итә, әлеге программа шуларны тормышка ашыруга юнәлдерелгән.

Программа барлык яшь гражданнарның ихтыяҗларын, үткәрелә торган чараларның адреслылыгын исәпкә алып төзелә, яшь буынны үстерүдә уңай тенденцияләргә ярдәм итүгә юнәлдерелгән.

2019 ел башына шәһәрдә 14 яшьтән 30 яшькә кадәрге 95 мең яшь кеше яши, шул исәптән югары белем бирү йортлары студентлары – 14088 һәм 13436 – урта һөнәри белем бирү йортлары студентлары. Яшьләр шәһәрдә яшәүчеләрнең 18 % ын тәшкил итә.

Шәһәр студентлары – шәһәр халкының шәһәр хакимияте ягыннан аерым игътибар таләп итә торган мобиль категориясе. Муниципалитет, һөнәри белем бирү оешмалары һәм югары белем бирү оешмалары ресурсларын берләштерү генә студентлар алдында да, гомумән шәһәр алдында да торган иң кискен проблемаларны мөмкин кадәр нәтиҗәле һәм рациональ хәл итәргә мөмкинлек бирәчәк, бу исә, ахыр чиктә, социаль һәм икътисадый планда нәтиҗә бирәчәк.

Яр Чаллыда тәрбия эшенең күп дәрәҗәле системасы эшли, ул оешма җитәкчеләре советының ай саен үткәрелә торган киңәшмәләре, тәрбия

эшләре буенча проректорлар советының атналык утырышлары аша тормышка ашырыла. Студент яшьләр белән эшләү кысаларында иң мөһим һәм төп юнәлеш булып студентларга социаль ярдәм күрсәтү тора.

Шәһәр халкының креатив һәм талантлы яшь буынын тәрбияләү территория үсешенең хәлиткеч факторы булырга тиеш, әмма бу гына җитми, тиешле социаль климат, яшьләрне нәтиҗәле социализацияләү чаралары, аларда үсешкә, мөстәкыйльлеккә, җаваплылыкка, компетентлыкка һәм һөнәри осталыкка, коммуникатив һәм лидерлык сыйфатларына, гражданлык һәм патриотизм, югары әхлакый һәм мораль стандартларга омтылыш ачу зарур.

Шәһәрдә талантлы яшьләргә рухи-интеллектуаль тәрбия бирүгә һәм ярдәм итүгә аерым игътибар бирелә. Ел саен яшьләр һәм шәһәр халкы өчен «Яшьләр көне», «Җиңү көне», «Ватанны саклаучылар көне», «Хәрби хезмәткә чакырылучылар көне» кебек зур чаралар үткәрелә. Әмма яшьләрнең иҗади потенциалын тормышка ашыру камилләштерүгә мохтаҗ. Талантлы иҗади яшьләр вәкилләренең шәһәр иҗади конкурсларының сайлап алу һәм финал этапларында катнашуына карамастан, бу чаралар финанслау чикле булу аркасында барлык теләүчеләрне колачлый алмый.

Талантлы яшьләрне ачыклау һәм алга этәрү системасының, яшьләрне инновацион эшчәнлеккә җәлеп итү механизмнарының камил булмавы икътисадны һәм шәһәр тормышының башка өлкәләрен модернизацияләү буенча социаль-икътисадый өстенлекләрне гамәлгә ашыруны сизелерлек кыенлаштырырга мөмкин. Яшьләр арасында хокук бозуларны профилактикалау мәсьәләләрен хәл итүдә, тулаем шәһәр яшьләр сәясәтен тормышка ашырудагы кебек, иҗтимагый оешмалар һәм ирекле отрядлар ышанычлы партнер булып тора. Уңай тормыш кыйммәтләре формалашкан яшь кешенең төрле деструктив күренешләр һәм берләшмәләр йогынтысына эләгү ихтималы азрак.

Балалар һәм яшьләр хәрәкәте үсә, аларда катнашучылар саны 3000 кешедән артып китә. Иҗтимагый оешмалар һәм берләшмәләрнең эшен шәһәр иҗтимагый оешмалар үзәге һәм ирекләләр үсеше үзәге алып бара.

Яшьләрнең социаль инициативаларына тиешле дәрәҗәдә ярдәм күрсәтелми - яшьләрнең иҗтимагый-файдалы эшчәнлеген стимуллаштыру һәм бүләкләү чаралары эшләргә, яшьләр белән эшләүче белгечләрнең һөнәри осталыгын үстерү, кадрлар потенциалын саклап калу өчен шартлар тудырырга кирәк, бу исә шәһәрнең иҗтимагый хәрәкәтендә катнашучылар санын арттырырга мөмкинлек бирәчәк.

Дәүләт яшьләр сәясәте активистларының кадрлар резервын үстерү һәм аңа ярдәм итү максатыннан, Яр Чаллы шәһәрендә ел саен 20 исемле стипендия һәм шәһәр Хакименең 10 премиясе тапшырыла.

Эшкә урнашу яшьләр өчен мөһим мәсьәлә булып тора. Укучы һәм студент яшьләрне даими, вакытлыча һәм бер тапкыр эшкә урнаштыруда ярдәм итү максатыннан, укудан буш вакытта һәм каникуллар чорында шәһәр оешмалары һәм предприятиеләре белән кадрларга ихтыяҗны ачыклау буенча эш алып барыла. Кергән вакансияләр турында мәгълүмат көн саен мәгълүмат

ресурсларында урнаштырыла. Кадрлар әзерләү буенча проблема юк кебек тоела, әмма шуңа да карамастан күп кенә предприятиеләрдә эш урыннарына вакансияләр ачык. Димәк, яшьләрдә я мотивация юк, я алар шәһәр предприятиеләренә кирәкле һөнәрләрнең күптөрлелеге турында хәбәрдар түгел.

Шуңа күрә эшче һәм инженер һөнәрләрен популярлаштыру максатыннан Яр Чаллы шәһәрендә урта звено укучылары, студентлар һәм эшләүче яшьләр белән һөнәри юнәлеш бирү буенча актив эш алып барыла. Яшьләрнең "Таныш булыгыз-профессионаллар!», «Чаллыда эшлә!» һөнәри юнәлеш бирү проектлары тормышка ашырыла, аларның кысаларында предприятиенең җитештерү процессы һәм кадрлар составы белән якыннан танышу бара.

Шуңа бәйле рәвештә, эшләүче яшьләрнең актив тормыш позициясен һәм шәһәрнең иҗтимагый-сәяси тормышында катнашырга әзерлеген формалаштыру максатында, предприятиеләрдә, оешмаларда һәм учреждениеләрдә яшьләр белән эшләү структураларын булдыру буенча эшне активлаштырырга кирәк. Предприятиеләрдә яшьләр белән эш алып бару яшь хезмәткәргә һөнәри планда (техник проектлар, һөнәри осталык конкурслары, укыту) үсәргә мөмкинлек бирә, аның шәхес буларак үсешенә һәм үз-үзен релизацияләүгә ярдәм итә.

Яр Чаллы шәһәренең социаль-икътисадый үсеше мәсьәләләрен хәл итүдә кече һәм урта бизнес мөһим роль уйный. Эшмәкәрлеккә актив һәм сәләтле яшьләрне җәлеп итү, шулай ук яшь эшмәкәрнең уңай имиджын формалаштыру һәм популярлаштыру, яшьләрнең үзмәшгульлегенә ярдәм итү стимуллаштыру факторы булып тора. Моннан тыш, яшьләр арасында социаль тискәре күренешләрне профилактикалау дәүләт яшьләр сәясәтенең өстенлекле юнәлеше булып тора, наркоманлык, күзәтүчесезлек һәм хокук бозуларны профилактикалау, толерантлык формалаштыру, яшьләр арасында суицидларны профилактикалау, белгечләр, ата-аналар белән эшне оештыру, тикшеренү эше, ведомствоара хезмәттәшлек кебек мөһим юнәлешләр гамәлгә ашырыла.

Шулай итеп, бүген Яр Чаллы шәһәрендә яшьләр сәясәте, шәһәрнең социаль сәясәтендә өстенлекле юнәлешләрнең берсе буларак, системалы һәм тотрыклы характерга ия, яшь буынның үсешенә һәм аның проблемаларын хәл итүгә актив ярдәм итә.

Әмма шәһәрдә бу өлкәдә кайбер проблемалар да бар, алар арасында түбәндәгеләрне аерып күрсәтергә мөмкин:

1) яшьләр сәясәте инфраструктурасы җәмгыять куйган таләпләрдән һәм яшьләрнең ихтыяҗларыннан калыша;

2) талантлы яшьләр Россиянең эре шәһәрләренең һәм чит илләрнең югары уку йортларында белем алырга китә һәм, шуның нәтиҗәсе буларак, шәһәрдә югары квалификацияле кадрлар саны кими;

3) яшьләрне шәһәрнең социаль тормышына интеграцияләү һәм килгән яшьләрне яңа шартларга җайлаштыру проблемаларының булуы;

4) балигъ булмаганнар һәм яшьләр арасында җинаятьчелекнең арту тенденциясе кабат барлыкка килү.

Программада тәкъдим ителгән чаралар югарыда күрсәтелгән проблемаларны хәл итәргә ярдәм итә.

## 3 бүлек. Программаның максаты һәм бурычлары

Программаның төп максаты – яшьләрне социализацияләү һәм үз-үзләрен нәтиҗәле реализацияләү өчен кирәкле шартлар тудыру, бу шартларны ресурслар белән тәэмин итү һәм яшьләрне социаль яклау өчен гарантияләр булдыру.

Әлеге максатка ирешү өчен программа түбәндәге бурычларны тормышка ашырырга тиеш:

1) балаларның, яшүсмерләрнең һәм яшьләрнең ялын оештыру;

2) яшүсмерләрнең һәм яшьләрнең үз-үзләрен асоциаль һәм деструктив тотышларын профилактикалауга, социаль куркыныч хәлдә булган балаларга һәм яшьләргә ярдәм итүгә юнәлдерелгән чаралар оештыру;

3) мәгълүмати һәм психологик ярдәм күрсәтү, шул исәптән телефон аша;

4) талантлы һәм инициативалы яшьләрне үстерү системасын формалаштыруга, яшүсмерләрнең һәм яшьләрнең үз мөмкинлекләрен тормышка ашыру өчен шартлар тудыруга, яшүсмерләрнең һәм яшьләрнең иҗади, һөнәри, интеллектуаль потенциалын үстерүгә юнәлдерелгән яшьләр сәясәте өлкәсендә чаралар оештыру;

5) яшьләрне гражданлык һәм патриотик тәрбияләүгә, яшьләр арасында толерантлык тәрбияләүгә, яшьләр арасында хокукый, мәдәни һәм әхлакый кыйммәтләр формалаштыруга юнәлдерелгән яшьләр сәясәте өлкәсендә чаралар оештыру;

6) яшьләрне инновацион, эшмәкәрлек, ирекле эшчәнлеккә җәлеп итүгә, шулай ук яшьләрнең граждан активлыгын үстерүгә һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыруга юнәлдерелгән яшьләр сәясәте өлкәсендә чаралар оештыру;

7) яшүсмерләрдә һәм яшьләрдә эшмәкәрлек күнекмәләрен формалаштыру максатында вакытлыча эшкә урнашуны оештыру һәм эшмәкәрлек нигезләренә практик өйрәтүне оештыруга ярдәм күрсәтү;

8) Яр Чаллы шәһәрендә дәүләт яшьләр сәясәте активистларының кадрлар резервына ярдәм итү һәм аны үстерү.

## 4 бүлек. Программаны тормышка ашыру сроклары һәм этаплары

Программаны тормышка ашыру өч елга исәпләнгән – 2020-2022 еллар.

## 5 бүлек. Программаны ресурслар белән тәэмин итү

2020-2022 елларга Программаны финанслау күләме 406932,58 мең сум.

Программаны финанслау чыганагы булып Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты тора.

Барлык чорга 406932,58 мең сум, шул исәптән Программаны тормышка ашыру елларына бүлеп:

2020 ел – 136 580,23 мең сум, 2021 ел – 135 117,76 мең сум, 2022 ел – 135 234,59 мең сум.

Финанслау күләме прогноз характерында һәм аңа агымдагы финанс елына һәм план чорына Яр Чаллы шәһәре бюджеты проектын формалаштырганда төгәллек кертелергә тиеш.

## 6 бүлек. Программа чаралары системасы

Программа чаралары яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру өлкәсендә Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының хезмәт күрсәтүләр һәм хезмәтләр база (тармак) исемлеге, норматив документлары нигезендә билгеләнгән.

Программа чаралары системасы түбәндәге юнәлешләр буенча эшләрне берләштерә:

1) яшүсмерләрнең һәм яшьләрнең үз-үзләрен асоциаль һәм деструктив тотышларын профилактикалауга, социаль куркыныч хәлдә булган балаларга һәм яшьләргә ярдәм итүгә юнәлдерелгән чаралар оештыру;

2) яшьләр сәясәте өлкәсендә талантлы һәм инициативалы яшьләрне үстерү системасын формалаштыруга, яшүсмерләргә һәм яшьләргә үз-үзләрен реализацияләү өчен шартлар тудыруга, иҗади, һөнәри, интеллектуаль потенциалларын үстерүгә юнәлдерелгән чаралар оештыру;

3) яшьләр сәясәте өлкәсендә яшьләрдә гражданлык һәм патриотик хисләр тәрбияләүгә, яшьләр арасында толерантлык тәрбияләүгә, хокукый, мәдәни һәм әхлакый кыйммәтләрне формалаштыруга юнәлдерелгән чаралар оештыру;

4) яшьләр сәясәте өлкәсендә яшьләрне инновацион, эшмәкәрлек, иреклелек (волонтерлык) һәм башка социаль әһәмияткә ия эшчәнлеккә җәлеп итүгә, шулай ук яшьләрнең гражданлык активлыгын үстерүгә һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыруга, шулай ук яшьләрнең белем алулары өчен шартлар тудыруга юнәлдерелгән чаралар оештыру;

5) яшьләргә үсү өчен өчен уңайлы мәгълүмат кыры формалаштыру, дәүләт структуралары, иҗтимагый берләшмәләр һәм яшьләр арасында кире элемтә механизмнарын булдыру, шулай ук яшьләргә патриотик һәм гражданлык тәрбиясе бирү өчен мәгълүмати инфраструктураны куллануның нәтиҗәлелеген арттыру;

6) яшь гаиләләр өчен уңай шартлар тудыру һәм гаилә культурасы кыйммәтләрен һәм уңышлы яшь гаилә образын формалаштыруга юнәлдерелгән чаралар оештыру, яшь гаиләләргә һәрьяклап ярдәм итү;

7) сәламәт яшәү рәвеше кыйммәтләрен формалаштыру, яшьләрнең физик үсеше өчен шартлар тудыру, экологик культура формалаштыру, шулай ук яшьләрнең тормыш иминлеге культурасы дәрәҗәсен күтәрү.

## 7 бүлек. Нәтиҗәлелекне бәяләү индикаторлары

Программаны тормышка ашыруның сан күрсәткече булып нәтиҗәлелек индикаторлары белән үлчәнә торган максатка ирешү тора:

| т/с | Күрсәткечләрнең исеме | Хисап формуласы | Чыганак |
|---|---|---|---|
| 1. | Яшьләрнең гомуми санына карата яшьләр сәясәте муниципаль учреждениеләре эшчәнлегенә җәлеп ителгән 14 яшьтән 30 яшькә кадәрге яшьләрнең саны, % | $C = \frac{C1 x 100\%}{C2}$<br>монда<br>С1 - яшьләр сәясәте муниципаль учреждениеләре эшчәнлегенә җәлеп ителгән кешеләр саны<br>С2 – Яр Чаллы шәһәрендә 14 яшьтән 30 яшькә кадәрге яшьләрнең гомуми саны | Яшьләр сәясәте муниципаль учреждениеләренең эшчәнлеге турында хисап |

## 8 бүлек. Программаны тормышка ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләү

Программа 2020-2022 елларга муниципаль яшьләр программасы чараларына җәлеп ителгән14 яшьтән 30 яшькә кадәрге яшьләрнең санын Яр Чаллы шәһәрендәге яшьләрнең гомуми санына карата 76,5 % дәрәҗәсендә сакларга мөмкинлек бирәчәк. Программада куелган максатны үтәүгә ирешүне характерлаучы сыйфат күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:

1) яшьләр сәясәте муниципаль учреждениеләре эшчәнлегенең төп юнәлешләре буенча чараларны үтәү проценты – 90% тан ким түгел;

2) яшүсмерләр һәм яшьләрнең үз-үзләрен асоциаль һәм деструктив тотышларын профилактикалауга юнәлдерелгән чаралар санын арттыру, аларда катнашучы балалар һәм яшьләр санын 20 мең кешегә кадәр җиткерүгә исәпләп;

3) яшьләр сәясәте өлкәсендә югары белемле кадрлар өлешен арттыру - хезмәткәрләрнең гомуми санынннан 90% ка кадәр;

4) конкурс чараларында катнашучы балалар һәм яшьләр санын арттыру-база чорыннан 5% ка;

5) чараларда катнашучы үзгә социаль төркемдәге балалар һәм яшьләр санын 300 кешегә кадәр арттыру;

6) ирекле эшчәнлектә катнашучы яшьләр санын арттыру - база чорыннан 5% ка.

Программаны практик тормышка ашыру түбәндәгеләрне тәэмин итәргә тиеш:

1) шәһәрнең уңай социаль-икътисадый үзгәрешләрендә яшьләрнең ролен арттыру;

2) яшь гаилә институтын ныгыту, яшьләрнең торак-көнкүреш шартларын яхшырту;

3) хезмәт базарында яшьләрнең конкурентлыкка сәләтлелеген арттыру, яшьләрне эш белән тәэмин итү һәм һөнәри юнәлеш бирү;

4) яшьләр арасында җинаятьчелек, наркомания, эчкечелек һәм экстремизм кебек тискәре (социаль куркыныч) күренешләрнең дәрәҗәсен киметү;

5) программаларны, проектларны һәм клуб берләшмәләрен гамәлгә ашыру юлы белән муниципаль учреждениеләрнең күп профильлелеген саклап калу һәм үстерү;

6) телефоннан шалтыратуларны өзлексез эшкәртүне оештыру, көчләү яисә башка авыр тормыш хәлендә калган яшүсмерләргә һәм яшьләргә ашыгыч психологик ярдәм күрсәтү;

7) талантлы һәм сәләтле яшьләрне ачыклау һәм аларга ярдәм итүгә юнәлдерелгән чаралар үткәрү;

8) яшьләрнең интеллектуаль, әхлакый һәм иҗади потенциалын арттыру, милли үзаңын, гражданлык һәм патриотизмны үстерү;

9) яшьләр иҗтимагый берләшмәләре эшчәнлегендә катнашучы яшьләрнең санын саклап калу;

10) яшь гражданнар өчен мәгълүмати хезмәтләрне киңәйтү;

11) яшьләрнең эшлекле активлыгын һәм булдыклылыгын үстерү; яңа эш башлаучы эшмәкәрләргә бизнесны аякка бастырырга ярдәм итү һәм мәгълүмати ярдәм күрсәтү;

12) шәһәр яшьләренең гражданлык үсеше һәм үз-үзләрен социаль реализацияләү өчен уңайлы шартлар тудыру;

13) шәһәр предприятиеләрендә, оешмаларында һәм учреждениеләрендә яшьләр белән эшләүче структураларны үстерү.

Программаны тормышка ашыруның нәтиҗәлелеге күрсәткече булып яшьләрнең җәмгыятьтәге социаль-икътисадый хәлен яхшырту, яшьләр арасында социаль-тискәре күренешләрне киметү тора.

9 бүлек. Максатлар, бурычлар, нәтиҗәләрне бәяләүнең индикаторлары һәм 2020-2022 елларга муниципаль яшьләр программасын чаралар буенча финанслау

| Бурычның исеме | Төп чараларның исеме | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләүнең индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Башкаручылар | Индикаторларның зурлыгы | | | | Финанслау, финанс чыганагын күрсәтеп, мең сум | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2019 база | 2020 | 2021 | 2022 | 2020 | 2021 | 2022 |
| Максатның исеме: Яшьләрне социализацияләү һәм аларга үз-үзләрен нәтиҗәле реализацияләү өчен кирәкле шартлар тудыру | | | | | | | | Муниципаль бюджет | | |
| 2020-2022 елларга муниципаль яшьләр программасы чараларына җәлеп ителгән 14 яшьтән 30 яшькә кадәрге яшьләрнең саны,% | | | | 76,5 | 76,5 | 76,5 | 76,5 | - | - | - |
| Балаларның, яшүсмерләрнең һәм яшьләрнең ялын оештыру | Яшьләр өчен программалар, проектларны тормышка ашыру | Программалар, проектлар, саны берәмлек | «Заман» ЯҮ» МАУ | 7 | 7 | 7 | 7 | 127202,57 | 127317,1 | 127433,93 |
| | | | «Нур» ЯҮ» МАУ | 17 | 14 | 14 | 14 | | | |
| | | | «Орион» ЯҮ» МАУ | 13 | 13 | 13 | 13 | | | |
| | | | «Шатлык» ЯҮ» МАУ | 6 | 8 | 8 | 8 | | | |
| | | | «Яшүсмер» яшәү урыны буенча Я(Я)КҮ» МАУ | 77 | 10 | 10 | 10 | | | |
| | | | «Яр Чаллы СХОҮ» МАУ | 3 | 3 | 3 | 3 | | | |
| | | | «Диалог» БҺЯППЯҮ» МБУ | 11 | 7 | 7 | 7 | | | |
| | | | «Форпост» ҖТСбЯ(С)Ф үзәге» МБУ | 5 | 5 | 5 | 5 | | | |
| | Түгәрәкләр, секцияләр эшчәнлеген оештыру | Түгәрәкләр, секцияләр саны, берәмлек | «Заман» ЯҮ» МАУ | - | 9 | 9 | 9 | | | |
| | | | «Нур» ЯҮ» МАУ | - | 5 | 5 | 5 | | | |
| | | | «Орион» ЯҮ» МАУ | - | 3 | 3 | 3 | | | |
| | | | «Шатлык» ЯҮ» МАУ | - | 7 | 7 | 7 | | | |
| | | | «Яшүсмер» яшәү урыны буенча Я(Я)КҮ» МАУ | - | 70 | 70 | 70 | | | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Шөгыльләнүчеләр саны, кеше | «Заман» ЯҮ» МАУ | - | 400 | 400 | 400 | | | |
| | | | «Нур» ЯҮ» МАУ | - | 290 | 290 | 290 | | | |
| | | | «Орион» ЯҮ» МАУ | - | 45 | 45 | 45 | | | |
| | | | «Шатлык» ЯҮ» МАУ | - | 150 | 150 | 150 | | | |
| | | | «Яшүсмер» яшәү урыны буенча Я(Я)КҮ» МАУ | - | 2400 | 2400 | 2400 | | | |
| | Эшчәнлекне оештыру һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләренә ярдәм күрсәтү | Иҗтимагый берләшмәләр саны, берәмлек | «Заман» ЯҮ» МАУ | - | 2 | 2 | 2 | | | |
| | | | «Нур» ЯҮ» МАУ | - | 7 | 7 | 7 | | | |
| | | | «Орион» ЯҮ» МАУ | - | 9 | 9 | 9 | | | |
| | | | «Шатлык» ЯҮ» МАУ | - | 2 | 2 | 2 | | | |
| | | | «Яшүсмер» яшәү урыны буенча Я(Я)КҮ» МАУ | - | 2 | 2 | 2 | | | |
| | | Шөгыльләнүчеләр саны, кеше | «Заман» ЯҮ» МАУ | - | 40 | 40 | 40 | | | |
| | | | «Нур» ЯҮ» МАУ | - | 232 | 232 | 232 | | | |
| | | | «Орион» ЯҮ» МАУ | - | 180 | 180 | 180 | | | |
| | | | «Шатлык» ЯҮ» МАУ | - | 30 | 30 | 30 | | | |
| | | | «Яшүсмер» яшәү урыны буенча Я(Я)КҮ» МАУ | - | 70 | 70 | 70 | | | |
| | Яшьләр сәясәте учреждениеләре нең башка ял эшчәнлеге | Чаралар саны, берәмлек | «Заман» ЯҮ» МАУ | - | 35 | 35 | 35 | | | |
| | | | «Нур» ЯҮ» МАУ | - | 33 | 33 | 33 | | | |
| | | | «Орион» ЯҮ» МАУ | - | 65 | 65 | 65 | | | |
| | | | «Шатлык» ЯҮ» МАУ | - | 20 | 20 | 20 | | | |
| | | | «Яшүсмер» яшәү урыны буенча Я(Я)КҮ» МАУ | - | 70 | 70 | 70 | | | |
| | | Катнашучылар саны, кеше | «Заман» ЯҮ» МАУ | - | 6000 | 6000 | 6000 | | | |
| | | | «Нур» ЯҮ» МАУ | - | 2793 | 2793 | 2793 | | | |
| | | | «Орион» ЯҮ» МАУ | - | 3200 | 3200 | 3200 | | | |
| | | | «Шатлык» ЯҮ» МАУ | - | 600 | 600 | 600 | | | |
| | | | «Яшүсмер» яшәү урыны буенча Я(Я)КҮ» МАУ | - | 8000 | 8000 | 8000 | | | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Мәдәни-ял, спорт-массакүләм чаралар оештыру һәм үткәрү | Мәдәни-ял, спорт-массакүләм чаралар саны, берәмлек | «Заман» ЯҮ» МАУ | - | 28 | 28 | 28 | | | |
| | | | «Нур» ЯҮ» МАУ | - | 85 | 85 | 85 | | | |
| | | | «Орион» ЯҮ» МАУ | - | 15 | 15 | 15 | | | |
| | | | «Шатлык» ЯҮ» МАУ | - | 20 | 20 | 20 | | | |
| | | | «Яшүсмер» яшәү урыны буенча Я(Я)КҮ» МАУ | - | 600 | 600 | 600 | | | |
| | | Катнашучылар саны, кеше | «Заман» ЯҮ» МАУ | - | 1500 | 1500 | 1500 | | | |
| | | | «Нур» ЯҮ» МАУ | - | 10175 | 10175 | 10175 | | | |
| | | | «Орион» ЯҮ» МАУ | - | 1500 | 1500 | 1500 | | | |
| | | | «Шатлык» ЯҮ» МАУ | - | 9000 | 9000 | 9000 | | | |
| | | | «Яшүсмер» яшәү урыны буенча Я(Я)КҮ» МАУ | - | 10000 | 10000 | 10000 | | | |
| Яшүсмерләрнең һәм яшьләрнең асоциаль һәм деструктив тәртибен профилактикалауга юнәлдерелгән чаралар оештыру, социаль куркыныч хәлдә булган балаларга һәм яшьләргә ярдәм итү; | Яшьләр мохитендә асоциаль һәм деструктив тәртипне профилактикалау чаралар үткәрү | Чаралар саны, берәмлек | «Заман» ЯҮ» МАУ | - | 25 | 25 | 25 | | | |
| | | | «Нур» ЯҮ» МАУ | - | 40 | 40 | 40 | | | |
| | | | «Орион» ЯҮ» МАУ | - | 15 | 15 | 15 | | | |
| | | | «Шатлык» ЯҮ» МАУ | - | 20 | 20 | 20 | | | |
| | | | «Яшүсмер» яшәү урыны буенча Я(Я)КҮ» МАУ | - | 200 | 200 | 200 | | | |
| | | | «Диалог» БҺЯППЯҮ» МБУ | - | 100 | 100 | 100 | | | |
| | | | «Форпост» ҖТСбЯ(С)Ф үзәге» МБУ | - | 7 | 7 | 7 | | | |
| | | | «Яшьләр ышаныч телефоны» БЯТЭПЯҮ» МБУ | - | 1 | 1 | 1 | | | |
| | | Җыелган һәм эшкәртелгән статистик мәгълүматлар саны, берәмлек | «Яшьләр ышаныч телефоны» БЯТЭПЯҮ» МБУ | - | 2 | 2 | 2 | | | |
| | | | «Диалог» БҺЯППЯҮ» МБУ | - | 1200 | 1200 | 1200 | | | |
| | | | «Заман» ЯҮ» МАУ | - | 26 | 26 | 26 | | | |
| | | | «Нур» ЯҮ» МАУ | - | 42 | 42 | 42 | | | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | «Орион» ЯҮ» МАУ | - | 17 | 17 | 17 | | | |
| | | | «Шатлык» ЯҮ» МАУ | - | 22 | 22 | 22 | | | |
| | | | «Яшүсмер» яшәү урыны буенча Я(Я)КҮ» МАУ | - | 202 | 202 | 202 | | | |
| | | | «Форпост» ЖТСбЯ(С)Ф үзәге» МБУ | - | 9 | 9 | 9 | | | |
| Мәгълүмати һәм психологик ярдәм күрсәтү, шул исәптән телефон аша | Индивидуаль һәм төркемле консультацияләр, методик консультацияләр, телефон буенча консультацияләр оештыру һәм үткәрү | Консультацияләр саны, берәмлек | «Диалог» БҺЯППЯҮ» МБУ | - | 200 | 200 | 200 | | | |
| | | | «Яшьләр ышаныч телефоны» БЯТЭПЯҮ» МБУ | - | 4500 | 4500 | 4500 | | | |
| | | Эшкәртелгән чакырулар саны | «Яшьләр ышаныч телефоны» БЯТЭПЯҮ» МБУ | - | 7500 | 7500 | 7500 | | | |
| Талантлы һәм инициативалы яшьләрне үстерү системасын формалаштыруга, яшүсмерләрнең һәм яшьләрнең үз мөмкинлекләрен тормышка ашыру өчен шартлар тудыруга, яшүсмерләрнең | Талантлы һәм инициативалы яшьләргә ярдәм күрсәтү системасын формалаштыруга һәм үстерүгә юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыру | Чаралар саны, берәмлек | «Заман» ЯҮ» МАУ | - | 65 | 65 | 65 | | | |
| | | | «Нур» ЯҮ» МАУ | - | 50 | 50 | 50 | | | |
| | | | «Орион» ЯҮ» МАУ | - | 15 | 15 | 15 | | | |
| | | | «Шатлык» ЯҮ» МАУ | - | 40 | 40 | 40 | | | |
| | | Мәгълүмати-аналитик материаллар саны, | «Заман» ЯҮ» МАУ | - | 1 | 1 | 1 | | | |
| | | | «Нур» ЯҮ» МАУ | - | 1 | 1 | 1 | | | |
| | | | «Орион» ЯҮ» МАУ | - | 1 | 1 | 1 | | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| һәм яшьләрнең иҗади, һөнәри, интеллектуаль потенциалын үстерүгә юнәлдерелгән яшьләр сәясәте өлкәсендә чаралар оештыру | | берәмлек | «Шатлык» ЯҮ» МАУ | - | 1 | 1 | 1 | | |
| | | Үткәрелгән мониторинглар саны, берәмлек | «Заман» ЯҮ» МАУ | - | 2 | 2 | 2 | | |
| | | | «Нур» ЯҮ» МАУ | - | 5 | 5 | 5 | | |
| | | | «Орион» ЯҮ» МАУ | - | 2 | 2 | 2 | | |
| | | | «Шатлык» ЯҮ» МАУ | - | 2 | 2 | 2 | | |
| | | Эш нәтиҗәләре буенча төзелгән хисаплар саны, берәмлек | «Заман» ЯҮ» МАУ | - | 66 | 66 | 66 | | |
| | | | «Нур» ЯҮ» МАУ | - | 50 | 50 | 50 | | |
| | | | «Орион» ЯҮ» МАУ | - | 15 | 15 | 15 | | |
| | | | «Шатлык» ЯҮ» МАУ | - | 40 | 40 | 40 | | |
| Яшьләрне гражданлык һәм патриотик тәрбияләүгә, яшьләр арасында толерантлык тәрбияләүгә, яшьләр арасында хокукый, мәдәни һәм әхлакый кыйммәтләр формалаштыруга юнәлдерелгән яшьләр сәясәте өлкәсендә чаралар оештыру | Яшьләрне гражданлык һәм патриотик тәрбияләүгә юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыру | Чаралар саны, берәмлек | «Заман» ЯҮ» МАУ | - | 36 | 36 | 36 | | |
| | | | «Нур» ЯҮ» МАУ | - | 49 | 49 | 49 | | |
| | | | «Орион» ЯҮ» МАУ | - | 15 | 15 | 15 | | |
| | | | «Шатлык» ЯҮ» МАУ | - | 50 | 50 | 50 | | |
| | | | «Форпост» ҖТСбЯ(С)Ф үзәге» МБУ | - | 116 | 116 | 116 | | |
| | | Җыелган һәм эшкәртелгән статистик мәгълүматлар саны, берәмлек | «Заман» ЯҮ» МАУ | - | 37 | 37 | 37 | | |
| | | | «Нур» ЯҮ» МАУ | - | 49 | 49 | 49 | | |
| | | | «Орион» ЯҮ» МАУ | - | 1 | 1 | 1 | | |
| | | | «Шатлык» ЯҮ» МАУ | - | 50 | 50 | 50 | | |
| | | | «Форпост» ҖТСбЯ(С)Ф үзәге» МБУ | - | 116 | 116 | 116 | | |
| | | Үткәрелгән мониторинглар саны, берәмлек | «Заман» ЯҮ» МАУ | - | 1 | 1 | 1 | | |
| | | | «Нур» ЯҮ» МАУ | - | 1 | 1 | 1 | | |
| | | | «Орион» ЯҮ» МАУ | - | 1 | 1 | 1 | | |
| | | | «Шатлык» ЯҮ» МАУ | - | 1 | 1 | 1 | | |
| | | | «Форпост» ҖТСбЯ(С)Ф үзәге» МБУ | - | 1 | 1 | 1 | | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Яшьләрне инновацион, эшмәкәрлек, ирекле эшчәнлеккә җәлеп итүгә, шулай ук яшьләрнең граждан активлыгын үстерүгә һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыруга юнәлдерелгән яшьләр сәясәте өлкәсендә чаралар оештыру | Ирекле эшчәнлекне, социаль әһәмиятк ия инициативаларны үстерүгә юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыру | Чаралар саны, берәмлек | «Заман» ЯҮ» МАУ | - | 6 | 6 | 6 | | | |
| | | | «Нур» ЯҮ» МАУ | - | 20 | 20 | 20 | | | |
| | | | «Орион» ЯҮ» МАУ | - | 120 | 120 | 120 | | | |
| | | | «Шатлык» ЯҮ» МАУ | - | 30 | 30 | 30 | | | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Яшүсмерләрдә һәм яшьләрдә эшмәкәрлек күнекмәләрен формалаштыру максатында вакытлыча эшкә урнашуны оештыру һәм эшмәкәрлек нигезләренә практик өйрәтүне оештыруга ярдәм күрсәтү | Яшүсмерләрнең һәм яшьләрнең мәшгульлеген тәэмин итү; вакытлыча эшкә урнашуны оештыру | Вакытлыча эшкә урнаштыру буенча муниципаль хезмәттән файдаланган гражданнар саны, кеше | «Яр Чаллы СХОҮ» МАУ | 2000 | 2000 | 2000 | 2000 | 5800,66 | 5800,66 | 5800,66 |
| | | Вакытлы эшкә керешкән гражданнар саны, кеше | | 1500 | 1500 | 1500 | 1500 | | | |
| | | Хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итүчеләрнең гомуми саныннан эшкә урнашучылар өлеше, % | | - | 75 | 75 | 75 | | | |
| | Яшүсмерләр һәм яшьләр бизнес компанияләрен үстерүгә юнәлдерелгән чаралар үткәрү | Чаралар саны, берәмлек | | - | 4 тән ким түгел | 4 тән ким түгел | 4 тән ким түгел | | | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Яр Чаллы шәһәрендә дәүләт яшьләр сәясәте активистларының кадрлар резервына ярдәм итү һәм аны үстерү | Яшьләр сәясәте активистларын шәһәр Хакиме стипендияләре белән бүләкләү | Яшьләр сәясәте өлкәсендә адреслы ярдәмнән файдаланган лидерлар һәм активистлар саны, кеше | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе | 20 | 20 | 20 | 20 | 480,0 | 480,0 | 480,0 |
| | Яшьләр сәясәте өлкәсендә иң яхшы хезмәткәрләргә шәһәр Хакиме премиясен тапшыру | Яшьләр сәясәте өлкәсендә адреслы ярдәмнән файдаланган лидерлар һәм активистлар саны, кеше | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе | 10 | 10 | 10 | 10 | 260,4 | 260,4 | 260,4 |
| | Шәһәр чаралары, конкурслар, фестивальләр, хөрмәтләүләр, конференцияләр үткәрү, республика һәм бөтенроссия конкурсларында һәм чараларында катнашу | Чаралар саны, берәмлек | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе | 19 | 30 | 29 | 29 | 2836,6 | 1259,6 | 1259,6 |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы

Н.И. Галиева

МУНИЦИПАЛЬНОЕ КАЗЕННОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ «ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН» • ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ МУНИЦИПАЛЬ КАЗНА УЧРЕЖДЕНИЕСЕ
УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ